СОВЕТ САРМАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ САРМАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

04.09.2020 с. Сарманово № 252

**Сарман муниципаль районы берәмлекләр башлыкларының, муниципаль берәмлекләр башлыклары урынбасарларының, Сарман муниципаль районы Контроль-хисап палатасы рәисенең айлык акчалата түләү күләмнәрен арттыру турында**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы муниципаль берәмлекләр башлыкларының, муниципаль берәмлекләр башлыклары урынбасарларының, депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы органнары әгъзаларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең һәм муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладларының айлык акчалата түләү күләмнәрен арттыру турында» 2020 елның 6 августындагы 658 номерлы карары, «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Сарман муниципаль районы Советы КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. Сарман муниципаль районы берәмлекләре башлыкларының, муниципаль берәмлекләр башлыклары урынбасарларының, Сарман муниципаль районы Контроль-хисап палатасы рәисенең «Муниципаль берәмлекләр башлыкларының, Сарман муниципаль районы башлыклары урынбасарларының, Сарман муниципаль районы Контроль-хисап палатасы рәисенең хезмәт хакының иң чик күләмнәрен раслау турында» Сарман муниципаль районы Советының 2018 елның 14 маендагы 122 номерлы карары белән расланган карары нигезендә , 2020 елның 1 октябреннән айлык акчалата түләү күләмен 1,03 тапкырга арттырырга (Сарман муниципаль районы Советының 2018 елның 16 маендагы 148 номерлы карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән).

2. 1 нче кушымтаның 1 нче абзацын Сарман муниципаль районы Советының 2018 нче елның 14 нче маендагы 122 нче номерлы карарын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы муниципаль берәмлекләр башлыкларына, депутатларга, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларына айлык акчалата түләү күләмнәре:

| Вазыйфа исеме | Айлык акчалата түләү күләме, сум | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | 8 төркем* | 9 төркем* | 10 төркем* | 11 төркем* | 12 төркем* |
| Муниципаль берәмлек башлыгы | 30 442 | 21 394 | 18 748 | 17 253 | 15 759 |
| Муниципаль берәмлек башлыгы урынбасары | 27 398 | 17 062 | 13 968 | 12 398 | 11 499 |
| Депутат | 14 927 | 11 498 | 11 498 | 11 498 | 11 498 |
| Җирле үзидарәнең сайлау органы әгъзасы | 12 684 | 11 498 | 11 498 | 11 498 | 11 498 |

3. Әлеге карарны гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү тиешле финанс елына җирле бюджетларда каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

4. Җирле үзидарә органнары һәм муниципаль орган җитәкчеләренә үзләре чыгарган хокукый актларны әлеге карарга туры китерүне йөкләргә.

5.Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм «Интернет» мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендә «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында урнаштырырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Сарман муниципаль районы Советының законлылык, хокук тәртибе һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Сарман муниципаль районы
Советы Рәисе — Ф. М. Хөснуллин